| | |
|---|---|
| **Татарстан Республикасы**<br>**Арча муниципаль районының**<br>**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**<br>**Арча шәһәр**<br>**башкарма комитеты**<br><br>**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**<br>**тел. 3-16-25, 3-12-35** | **Муниципальное образование**<br>**город Арск**<br>**Арского муниципального района**<br>**Республики Татарстан**<br>**исполнительный комитет**<br>**города Арск**<br>**422000, г. Арск, площадь Советская, 27**<br>**тел. 3-16-25, 3-12-35** |

# КАРАР

**« 22 » апрель 2026 ел** **№ 46**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитетының “Белешмә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2024 елның 23 ноябрендәге 167 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

”Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча шәһәре башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча шәһәре башкарма комитетының “Белешмә (күчермә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2024 елның 23 ноябрендәге 167 номерлы карары белән расланган белешмә (күчермә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктындагы 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк булган очракта һәм федераль закон нигезендә мондый шәхси күрсәткечләрне эшкәртү күрсәтелгән зат ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, муниципаль хезмәтне алу өчен мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртүгә ризалыгын алуын раслый торган өстәмә документлар тапшыра. Ризалык алуны раслый торган документлар шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшырылырга мөмкин;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру

юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре башкарма комитетының әйдәп баручы белгече Г.Х.Билаловага йөкләргә.

Арча шәһәре
башкарма комитеты җитәкчесе Р. Р. Баһаветдинов